ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.02.2026 Олы Кайбыч ав. №101

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Олы Урсак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында

Халыкның җир кишәрлекләре хокукына ия булучыларының тормыш эшчәнлеген, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен уңай шартларга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Олы Урсак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Олы Урсак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлауларны 2026 елның 17 февралендә:

- 14.00 сәгатьтә Кайбыч районы, Олы Урсак авылы, Җиһаншин ур., 74 й. адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында;
- 15.00 сәгатьтә Кайбыч районы, Кече Урсак авылы, Усманов ур., 46 й. адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында уздырырга.

3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Олы Урсак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты материаллары белән (текст һәм график өлеш) эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр:

Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 йорт, 2 кат, 209 кабинет;

- Татарстан Республикасы Кайбыч районы, Олы Урсак авылы, Җиһаншин ур., 74 й.;
- Татарстан Республикасы Кайбыч районы, Кече Урсак авылы, Усманов ур., 46 й.;

- Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Бушанчы авылы, Совет ур., 24;
- Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Чүкри Алан авылы, Җәлил ур., 7 й. адресы буенча танышырга мөмкин.

3.1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Олы Урсак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре карар проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җыю урыны итеп:

- Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 йорт, 2 кат, 209 кабинет адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеген;

- Кайбыч районы, Олы Урсак авылы, Җиһаншин ур., 74 й. адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Урсак Башкарма комитетын билгеләргә.

4. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә:

- Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Олы Урсак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре карар проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга;

әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Е.Г. Давыдовага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров